Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020 ел № 5

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 122 номерлы «Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 122 номерлы «җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Билгеләү:

4.1. Календарь елы салым чоры дип таныла.

4.2. Салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы таныла.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб – адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы
вазифасын вакытлыча башкаручы Р. Р.Маликова

Совет Большеатнинского сельского поселения
Олы Әтнә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000571